ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

22.08.2019 г. Казань № 246-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертем счетлары) ачарга һәм аларга ия булырга, нал белән акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга рөхсәт ителми торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары Исемлеген раслау турында

«Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертем счетлары) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалану тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты “и” пунктчасы белән, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы торуның кайбер мәсьәләләре турында» 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, аларны алмаштырганда Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булу, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Указы белән туры килеп б о е р а м :

1. Кушылып бирелгән Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертем счетлары) ачарга һәм аларга ия булырга, нал белән акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга рөхсәт ителми торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары Исемлеген расларга ( алга таба – Исемлек)

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире О.А. Филипповага Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә, әлеге боерыкның 1 пункты нигезендә расланган Исемлекне, исемлек расланган көннән алып өч көн эчендә, ә алга таба, аларга үзгәрешләр керткәндә, төгәлләштерелгән Исемлекләрне үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә тапшырырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис Ф.С.Батков

22.08.2019 елдан 246-од
номерлы
Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертем счетлары) ачарга һәм аларга ия булырга, нал белән акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга рөхсәт ителми торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары Исемлеге

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган, Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына кертелгән, вазыйфаларның иң югары төркеменә керә:

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары ( 2 вазыйфа)

---